Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл Советы

КАРАР

16 июль 2024 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 106

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының 2022 елның 20 январендагы 38 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә

Бута авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының 2022 елның 20 январендагы 38 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Советының 2022 елның 13 июлендәге 50 номерлы, 2023 елның 26 сентябрендәге 81 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада 14 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункты белән тулыландырырга:

«11.1) чит ил агенты статусын алу;»

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Бута авылы, Сельская урамы, 28А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълумат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бута авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын
башкаручы　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Д.А. Ульдияров